# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **24 ноябрь 2025 ел.**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Алферовка торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Алферовка торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Алферовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә бер тапкыр түләүне, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, юл кырыйларын трактор белән чабу).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан: Алферовка авылы, Зеленая ур,5 мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирлеге Башлыгы А.П. Курганская